СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.08.2023 ел Баулы шәһәре № 199

“Татарстан Республикасы Баулы муниципаль
районы Кырымсарай авыл җирлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен
раслау турында” 2021 елның 6 августындагы
67 номерлы Баулы муниципаль район
Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2021 елның 6 августындагы 67 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Кырымсарай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 статьяның 5 пунктында “Кырымсарай авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет)” сүзләрен “Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет)” сүзләре белән алмаштырырга;

8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Баулы муниципаль районы Кырымсарай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

«1.Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль районы Уставына, “Кырымсарай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә билгеләнә.

2. Баулы муниципаль районы Советының җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә керә:

- Баулы муниципаль районы «Кырымсарай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау, шул исәптән үзгәрешләр (өстәмәләр) кертү;

- Баулы муниципаль районы Кырымсарай авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау, шул исәптән үзгәрешләр (өстәмәләр) кертү;

- Кырымсарай авыл җирлегенең генераль планын раслау, шул исәптән үзгәрешләр (өстәмәләр) кертү;

- җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә вазифаи затларының җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәвен контрольдә тоту;

3. Баулы муниципаль районы Кырымсарай авыл җирлеге Советының җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә керә:

- Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы һәм “Кырымсарай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

4. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә керә:

- төзелешкә рөхсәт бирү (башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясе шәһәр кодексында каралган очраклардан тыш);

- генераль планны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, территорияне планлаштыру буенча документацияне эшләүне оештыру, аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклардан тыш, шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын;

- муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә хәбәрнамәләр җибәрү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш)

- территорияне планлаштыру буенча документацияне раслау (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклардан тыш һәм башка федераль законнар белән)

- муниципаль берәмлек территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системасын алып бару;

- муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль берәмлек чикләрендәге җир кишәрлекләрен резевлау һәм алу;

- капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү

- җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү;

- индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү планлаштырылуы турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектының планлаштырылган төзелеш параметрлары турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамәләр, индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының төзелгән яки реконструкцияләнгән объектының җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында закон таләпләренә туры килү-килмәве турында хәбәрнамәләр;

- җирләрне, җирле әһәмияттәге су объектларын, җирле әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү өчен киң таралган файдалы казылмалар, җир асты ятмаларын кулллануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләренә шулай ук түбәндәгеләр керә:

- җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү;

- рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү.

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә Кырымсарай авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә керә:

- үз белдеге белән төзелешне сүтү турында Карар кабул итү яисә гражданлык законнарында каралган очракларда үз белдеге белән төзелешне сүтү яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда үз белдеге белән төзелешне сүтүне яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру;

- гамәлдәге законнар, “Кырымсарай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына, Баулы муниципаль районы Кырымсарай авыл җирлеге Советы карарларына ярашлы билгеләнгән, җирле әһәмияттәге сораулар буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Башкарма комитетның җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләре, әлеге статьяда закон нигезендә яки килешү буенча күрсәтелгән, шәһәр төзелеше эшчәнлеге, муниципаль милек, җир ресурслары белән идарә итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшырылырга мөмкин.”;

23 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Кызыксынган кешеләрнең язма нәтиҗәләрен кабул итүнең соңгы көненнән соң ун көн узгач Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты кызыл линияләр проектын расларга, эшләп бетерү өчен җибәрергә яки кире кагарга мөмкин;

25 статьяның 2 пунктындагы 3 подпунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир участогында ярдәмче файдаланудагы корылмаларны төзү, аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;»;

25 статьяның 2 пунктындагы 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхси торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү (“Күпфатирлы йортларның һәм башка күчемсез милек объектларының өлешчә төзелештә катнашуы һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, шәхси торак төзелеше объектларын төзүдән тыш өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп);

25 статьяның 2 пунктындагы 4.1.түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“капиталь төзелеш объектының капиталь төзекләндерүе, шул исәптән Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 11 бүлегендә билгеләнгән очракларда”;

26 статьяның 8 пунктындагы 18 абзацын “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 1 бүлегендәге “а” һәм “б” пунктларында билгеләнгән, атом энергиясен куллану объектларыннан тыш” сүзләре белән тулыландырырга;

27 статьяның 5 пунктындагы 5) пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«5.1) капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше тышкы күренешен килештерү, әгәр мондый килешү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган булса;»;

27 статьяның 5 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

‘‘мондый объектны реконструкцияләгән очракта капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7 пунктындагы 6.2 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш; күпфатирлы йортны реконструкцияләү очраклары, блокировкаланган төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, барлык бер рәттә булган блокировкаланган төзелеш йортларының хокук ияләренең ризалыгы;”;

27 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Шәхси торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү максатларында («Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, шәхси торак төзелеше объектларын төзүдән тыш) яки бакча йорты төзүчесе шәхси мөрәҗәгать аша Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша, кәгазьдә тапшыра яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталына тапшыру турында хәбәр белән почта аша шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү турында хәбәр җибәрә (алга таба шулай ук - планлаштырылган төзелеш турында хәбәр итү), анда түбәндәгеләр бар:

27 статьяның 9 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Төзелеш этабы белән бәйле төшенчә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына төгәл туры килә”;

28 статьяның 7 пунктында “башкарма документацияне алып баруның составы һәм тәртибе” сүзләрен төшереп калдырырга;

27 статьяның 12 пунктында “биш көн” сүзләрен “өч көн” сүзләренә алмаштырырга;

29 статьяның 3 пунктындагы 6 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төзелгән, реконструкция ясалган капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәренә тоташтыру (техник тоташтыру) (әгәр дә әлеге тоташтыру (техник тоташтыру) объектның проект документациясе буенча каралган булса) турында акт;»;

29 статьяның 5 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып:";

30 статьяның 3 пунктындагы 7 абзацында “Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче” сүзләрен “Россия

Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә, ул Россия Федерациясе тарафыннан барлыкка китерелгән яисә устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе өлеше 50 процентлан артык тәшкил итә, яисә устав (җыелма) капиталында өлеше 50 процентлан артык булган бүлендек җәмгыять тарафыннан шундый юридик затка карый" сүзләре белән алмаштырырга;

30 статьяның 3 пунктындагы 8 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе), территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе субъекты билгеләгән һәм Татарстан Республикасы кабул иткән территорияне комплекслы үстерү турында район Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек яисә уставлы (җыелма) капиталында Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек өлеше 50 процентлан артык тәшкил иткән территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән юридик зат яисә бүлендек җәмгыять, уставлы (җыелма) капиталында 50 процентлан артык өлеш шундый юридик затныкы, яки территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатыннан территорияне комплекслы үстерү турында килешү төзелгән затныкы.";

30 статьяның 9 пунктында "Кырымсарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башлыгына" сүзләрен "Баулы муниципаль районы Башлыгына" сүзләренә алмаштырырга;

30 статьяның 10 пунктында "Кырымсарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башлыгы" сүзләрен "Баулы муниципаль районы Башлыгына" сүзләренә алмаштырырга;

30 статьяның 15 пунктындагы беренче абзацта "Кырымсарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы" сүзләрен "Баулы муниципаль районы Советы" сүзләренә алмаштырырга;

30 статьяның 15 пунктындагы икенче абзацта "Кырымсарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы белән" сүзләрен "Баулы муниципаль районы Советы белән" сүзләре белән алмаштырырга;

30 статьяның 16 пунктында "Кырымсарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы" сүзләрен "Баулы муниципаль районы Советы" сүзләре белән алмаштырырга.

30 статьяның 17 пунктында "Кырымсарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы" сүзләрен "Баулы муниципаль районы Советы" сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында bavly.tatar.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының санитар-экологик куркынычсызлык һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров